ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.09.2022 п.г.т.Алексеевское № 386

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә урып-җыю кампаниясе чорында җирле бюджет хисабыннан бүләкләү рәвешендә грантлар бирү Тәртибе турында**

Хезмәт житештерүчәнлеген арттыруны стимуллаштыру һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 135, 191 статьялары нигезендә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләрен бүләкләүне оештыру максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясе чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә җирле бюджеттан бүләкләү рәвешендә грантлар бирү Тәртибен (кушымта) расларга.

2.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасына әлеге карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясе чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә җирле бюджеттан бүләкләү рәвешендә грантлар бирү тәртибе турында» 25.08.2021 ел, №306 Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
19.09.2022 елның
386 нчы карарына кушымта

**Урып-җыю кампаниясе чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә җирле бюджеттан бүләкләү рәвешендә грантлар бирү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип урып-җыю кампаниясе чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә җирле бюджеттан бүләкләү рәвешендә грантлар бирүнең максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели. Грант бирүнең максаты-Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясен уздыру барышында югары күрсәткечләргә ирешкән иң актив механизаторларны мотивацияләү.

2. Грантлар авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә, район башкарма комитеты карары белән расланган, Алексеевск муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясе чорында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлар) арасында конкурс үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә, конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә.

3. Грантлар урып җыю кампаниясе вакытында атна саен 7 июльдән 30 сентябрьгә кадәр түбәндәге номинацияләрдә бирелә:

- «Беренче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»: СК-5 Нива, Енисей, Нова;
- «Икенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»: Дон-1500, Вектор-410;
- «Өченче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»: Полесье, Акрос, Нью-Холланд, Кейс, Мега-204, Мега-208;
- «Дүртенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»: Тукано, Мега-370, Лексион, Торум;
- «Бөртекле һәм кузаклы культураларны чаптыруда үзйөрешле чапкычның иң яхшы механизаторы»: Макдон, КСУ-1,0;
- «Ындыр табагына комбайннан ашлык ташу буенча иң яхшы машина йөртүче»: КаМаз, МАЗ.

4. Грант бирүнең нәтиҗәсе-Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясен уздыру барышында югары күрсәткечләр. Грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр: җыеп алынган җир мәйданыннан (егәрлегенә карап файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасының аерым төркемнәре буенча) суктыру; чабылган мәйданның күләме; ташылган ашлык күләме;

5. Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты Алексеевск муниципаль районы территориясендә урып-җыю кампаниясе чорында авыл

хуҗалыгы хезмәткәрләре (механизаторлар) арасында конкурс үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә конкурс үткәрә.

6. Конкурс урып-җыю кампаниясе вакытында агымдагы елның 7 июленнән 30 сентябренә кадәр, түбәндәге номинацияләрдә һәр 7 көн саен үткәрелә:

- «Беренче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»;
- «Икенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»;
- «Өченче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»;
- «Дүртенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор»;
- «Бөртекле һәм кузаклы культураларны чаптыруда үзйөрешле чапкычның иң яхшы механизаторы»;
- «Ындыр табагына комбайннан ашлык ташу буенча иң яхшы машина йөртүче».

7. Катнашучыларга түбәндәге таләпләр куела:

7.1 «Беренче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- СК-5 Нива, Енисей, Нова комбайнында эшләр үткәрү.

7.2. «Икенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- Дон-1500, Вектор-410 комбайнында эшләр үткәрү;

7.3. «Өченче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- Полесье, Акрос, Нью-Холланд, Кейс, Мега-204, Мега-208 комбайнында эшләр үткәрү.

7.4. «Дүртенче төркем комбайнында эшләүче иң яхшы механизатор» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- Тукано, Мега-370, Лексион, Торум комбайнында эшләр үткәрү.

7.5. «Бөртекле һәм кузаклы культураларны чаптыруда үзйөрешле чапкычның иң яхшы механизаторы» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- Макдон и КСУ-1,0 чапкыч белән эш башкару.

7.6. «Ындыр табагына комбайннан ашлык ташу буенча иң яхшы машина йөртүче» номинациясенә:

- авыл хуҗалыгы предприятиесе яки КФХ хезмәткәре;
- КаМаз, МАЗ файдаланып эшләр үткәрү.

8. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү өчен түбәндәге составта конкурс комиссиясе төзергә:

Комиссия рәисе:

Гайнуллин О.А. - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

Комиссия әгъзалары:

Мусин Г.К. - Алексеевск муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Идарәсе башлыгы (килештерү буенча)

Михайлов Ю.В. -авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килештерү буенча)

Поповнин В.В. -авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты (килештерү буенча)

Шкильменская М.В. - Алексеевск авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Идарәсенең финанс-икътисад бүлеге консультанты (килештерү буенча)

9. Бәйгенең һәр чорында катнашу өчен заявкалар атна саен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек идарәсенә хисап чорының соңгы эш көнендә электрон рәвештә тапшырыла: alekseevsk.alsu@tatar.ru.Җыелган гаризалар көн ахырында конкурс комиссиясе рәисенә җибәрелә.

10. Комиссия утырышлары атна саен комиссия рәисе карары буенча үткәрелә. Комиссия карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

11. Грантлар,конкурс игълан ителгән айдан алдагы айның 1 нче көненә түбәндәге таләпләргә туры килгән авыл хуҗалыгы эшчеләренә бирелә :

а) грант алучыларның салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

б) грант алучыларның Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычы булмаска тиеш, аннан әлеге Тәртип нигезендә субсидияләр,бюджет инвестицияләре бирү планлаштырыла, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, һәм Алексеевск муниципаль районы бюджеты алдында бүтән кичектерелгән бурычы.

12. Комиссия конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны билгели һәм авыл хуҗалыгы техникасын куллануга карап алар арасында премияләр бүлеп бирә СК-5 Нива, Енисей, Нова:

1 урын – 2000 (ике мең) сум;

2 урын – 1000 (мең) сум.

Комиссия конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны билгели һәм авыл хуҗалыгы техникасын куллануга карап алар арасында премияләр бүлеп бирә Дон-1500, Вектор-410:

1 урын – 2000 (ике мең) сум;

2 урын – 1000 (мең) сум.

Комиссия конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны билгели һәм авыл хуҗалыгы техникасын куллануга карап алар арасында премияләр бүлеп бирә Полесье, Акрос, Нью-Холланд, Кейс, Мега-204, Мега-208:

1 урын – 2000 (ике мең) сум;

2 урын – 1000 (мең) сум.

Комиссия конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны билгели һәм авыл хуҗалыгы техникасын куллануга карап алар арасында премияләр бүлеп бирә Тукано, Мега-370, Лексион, Торум:

1 урын – 2000 (ике мең) сум;

2 урын – 1000 (мең) сум.

Комиссия конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны билгели һәм авыл хуҗалыгы техникасын куллануга карап алар арасында премияләр бүлеп бирә Макдон, КСУ-1,0:

1 урын – 2000 (ике мең) сум;

Комиссия конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны билгели һәм авыл хуҗалыгы техникасын куллануга карап алар арасында премияләр бүлеп бирә КаМаз, МАЗ:

1 урын – 2000 (ике мең) сум;

2 урын – 1000 (мең) сум.

13. Хезмәткәргә грант бирүдән баш тарту нигезе - аның әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән таләпләренә туры килмәве.

14. Район башлыгы грантлары Алексеевск районы бюджетында бүлеп бирелгән максатчан финанс чараларыннан түләнә һәм авыл хуҗалыгы кадрларының һөнәри үсешен һәм квалификациясен стимуллаштыру өчен билгеләнгән.

15. Грантлар түләү грантлар тапшырылганнан соң 15 эш көне эчендә грантка лаек булган затның банк счетына акча күчерү юлы белән башкарыла.

**Башкарма комитетның**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**